РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01 июня 2024ел.

КАРАР
№ 302

**Әтнә район башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннары арендалау шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2022 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминият фонды турында” 14.07.2022 №236 - ФЗ Федераль Законына, “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 15.08.2022 № 1415 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына таянып, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Әтнә районы Башкарма комитет карар итә:

1. Әтнә район башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннары арендалау шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2022 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары преамбуласында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән” сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. 3.3.2.1 пунктның 11 нче абзацы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр

кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал гаризаның дөрес тутырылмаган электрон формасы кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.”;

1.3. 2.6.1 пунктының 11 нче пунктчасында “Россия Федерациясе Пенсия фонды” сүзләрен “Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды” сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе А. Ф. Каюмов